КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 октябрь г.Казань № 1227

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 20 декабрь, 1012 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2015 ел, 29 апрель, 299 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 671 нче; 2016 ел, 23 июнь, 429 нчы; 2016 ел, 23 сентябрь, 682 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 1000 нче; 2017 ел, 7 февраль, 62 нче; 2017 ел, 15 февраль, 88 нче; 2017 ел, 8 июнь, 362 нче; 2017 ел, 26 июнь, 436 нчы; 2017 ел, 22 декабрь, 1028 нче; 2017 ел, 25 декабрь, 1030 нчы; 2018 ел, 21 май, 383 нче; 2018 ел, 24 сентябрь, 842 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1182 нче; 2019 ел, 8 апрель, 275 нче; 2019 ел, 3 июнь, 464 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 854 нче; 2020 ел, 27 гыйнвар, 24 нче; 2020 ел, 28 май, 437 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1086 нчы; 2021 ел, 30 июль, 666 нчы; 2022 ел, 19 май, 464 нче; 2022 ел, 20 июль, 699 нчы; 2022 ел, 6 сентябрь, 967 нче; 2023 ел, 1 июнь, 665 нче; 2023 ел, 14 июль, 831 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» дәүләт программасына 4 нче кушымтаның 6 графасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җаваплы республика башкарма хакимият органы»;

«2014 – 2025 елларга автомобиль юллары челтәрен камилләштерү, үстерү һәм саклау» ярдәмче программасында:

әлеге ярдәмче программаның 6 нчы кушымтасында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы паспортының 5 бүлегендәге «Төп килеп чыгу куркынычлары һәм мөмкинлекләр» юлында «ведомстволар эшен координацияләү хаталары» сүзләрен «җаваплы республика башкарма хакимият органы эшен координацияләү хаталары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге ярдәмче программаның 7 нче кушымтасында Яр Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасы паспортының 5 бүлегендәге «Төп килеп чыгу куркынычлары һәм мөмкинлекләр» юлында «ведомстволар» сүзен «җаваплы республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы транспорт комплексында дәүләт сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы паспортыннан соң җиденче абзацта «Татарстан Республикасы министрлыклары белән» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары белән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин